**МӘГАРИФ**

**АЙЛЫК ИҖТИМАГЫЙ-ПЕДАГОГИК һӘМ ФӘННИ-ӘДӘБИ ЖУРНАЛ**

ОЕШТЫРУЧЫЛАР: **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХӨКҮМӘТЕ, ХАЛЫК МӘГАРИФЕ МИНИСТРЛЫГЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

**№ 10 (680) ОКТЯБРЬ** 1918 елның ноябреннән чыга Татар телендә

# БУ САНДА

## АҢ-БЕЛЕМ ВӘ ЭШ-ГАМӘЛ

**Гомәрова Н.**— Үтемле алымнар куллансаң 2
**Исмәгыйлева С., Исмәгыйлева Ф.**— Тәрбия хәзинәләре 4
**Зубцова Л.**— Мөгаллимнәр нигә эш алыштыра 6
**Гайнетдинов Г.**— Педагогик колледж 7
**Класс җитәкчесенә**
**Сиражетдинова Л.**— Үзенчәлекләрне искә алу сорала 8

## БАШЛАНГЫЧ КЛАСС

Татар теленнән белем һәм күнекмәләрне бәяләү 10
**Мостафина Р.**— Мәсьәләләрне ничек чишәргә? 12

## РУС БАЛАЛАРЫНА ТАТАР ТЕЛЕ УКЫТУ

**Юсупов Ф., Казиханова З., Мөхиярова Р.**— II класс (Дәвамы) 13

## ТУГАН ТЕЛ һӘМ ӘДӘБИЯТ

**Гафарова С.**— Дәрестә күңел сафлана 17
**Зәйнуллина Ә., Нигъмәтуллов М.**— Татар теленнән контроль эшләр 19
**Мортазина Р.**— Камиллеккә омтылыш 20
**Сәгыйтов Р.**— Татар теле синонимиясендә гарәп-фарсы алынмалары 22
**Галимуллин Ф.**— Дилбегәне кем тоткан? 23

## РУССКОЕ СЛОВО

**Воронцова Т.**— Лирика Ф. И. Тютчева в X классе 25
**Ахбарова Г., Скиргайло Т.**— Уроки внеклассного чтения в VIII классе 28
Нормы оценки знаний, умений и навыков по русскому языку учащихся V—XI классов 30
**Гарифьянова Р.**— Могут ли учащиеся овладеть видовыми формами глагола? 34

## КУЛЬТУРА И ИСТОРИЯ ТАТАРСТАНА

**Амирханов Р.**— Развитие народного образования у татар в дооктябрьский период 35

## ГЫЙЛЕМ ДӨНЬЯСЫНДА

**Галиева Н., Подавалов А.**— Химиядән блок-практикум 39
**Фотеева И.**— «Кеше һәм җәмгыять» курсына темалар 42
**Абзалов Р., Яруллин Р.**— Физкультура дәресләрендәге яңалыклар 43
**Хәйруллин Г.**— «Дин тарихы» дәресләре 44

## КЛАССТАН ТЫШ ЭШЛӘР

**Таҗиев С.**— Кемнәр ул — «Лачыннар»? 48
**Хәйруллина А.**— Ягез әле, математиклар! 49

## МӘКТӘПКӘЧӘ ТӘРБИЯ

**Борһанова Р.**— Тәрбиячеләрнең методик берләшмәләре 51

## СЕЗГӘ, ӘТИ-ӘНИЛӘР, МӨГАЛЛИМНӘР

**Әхмәтҗанов М.**— Аналар һәм балалар 53
**Фәхретдин Р.**— Нәсихәт (Дәвамы) 55
**Камалов Б.**— Ата-ана, әби-бабай хакы 57
**Баязитова Ф.**— Туй алды йолалары һәм йола сүзләре 58
**Сафиуллина Г.**— Гаилә бәйрәмнәре 60
**Яшь талантлар**
**Мөслимова Ф.**— Илаһият 61
**Сезгә кирәкле китаплар** 62
**Безнең календарь** 63
**Ял сәгатьләрендә** 64

Баш мөхәррир
Фәрит ШӘРИФУЛЛИН

Редколлегия

Румин АКБАШЕВ,
Мәҗит ВӘЛИУЛЛИН
(баш мөхәррир урынбасары),
Тихния ГАЙФУЛЛИНА,
Миркасыйм ГОСМАНОВ,
Рәшит ИСЛАМШИН,
Зофәр МИФТАХОВ,
Гайнан МӨХӘММӘТҖАН
(җаваплы сәркатип),
Айдар САФИН,
Роза СЫРОМОЛОТОВА,
Фарис ХАРИСОВ,
Рамил ХӘЛИУЛЛИН,
Камәрия ХӘМИДУЛЛИНА,
Рүзәл ЮСУПОВ,
Фәүзия ЮСУПОВА,
Фәрит ЮСУПОВ,
Миңнехан ӘХМӘТҖАНОВ.

Бүлек мөхәррирләре:
Ә. М. ЛАТЫЙПОВ (туган тел һәм әдәбият, төрле фәннәр).
М. ШӘФИГУЛЛИНА (рус теле һәм әдәбияты, мәктәпкәчә тәрбия)
Гыйльми мөхәррир:
ХӘЙРУЛЛИНА (физика, математика, башлангыч мәктәп).
Мөхәррир.
Х. ВӘЛИЕВ (педагогика-методика, мәктәп һәм гаилә)
Бизәлеш мөхәррире:
Ә. МОРГАЦКАЯ

Телефоннар:
Баш мөхәррир 53-57-35
Баш мөхәррир урынбасары 53-39-15
Җаваплы сәркатип 53-07-82
Бүлек мөхәррирләре 53-07-80
53-07-78



**Хатлар өчен адрес:**
420066, Казань,
ул. Декабристов, 2.
Редакция журнала «Мәгариф», а/я 47

© 1992 ел

# ТӘРБИЯ ХӘЗИНӘЛӘРЕ

**Халкыбызның яшь буынга тәгълим-тәрбия бирү тәҗрибәсен җентекләп өйрәнү гаять мөһим. Әхлак тәрбиясе нигезләре, шәхесне сафландыручы гореф-гадәтләр, йолалар, традицияләр турында хәбәрдар булу, бу гаҗәеп бай һәм гыйбрәтле рухи-мәдәни хәзинәбездән үзебезнең тормыш-көнкүрешебездә файдалану, кирәк икән, аны яңарту, үзгәртү бүгенге көндә нәтиҗәсез кулланылган тәрбия ысулларыбызга, чараларыбызга билгеле бер дәрәҗәдә җан өрер, мәгънәле, тәэсирлерәк итәр иде.**

**«Халкыбызның тәгълим-тәрбия тәҗрибәсе» дигәннән нәрсәне аңларга соң? Аны өйрәнү белән кайсы фән шөгыльләнә? Татар халкының, йөзләгән, меңләгән еллар буена тудырып, буыннан-буынга тапшыра килгән бала тәрбияләү тәҗрибәсендә нинди уңай традицияләр бар?**

**Халык педагогикасы турындагы әңгәмәләр күпмедер дәрәҗәдә шул сорауларга җавап бирә. Алар ата-аналарга, укытучыларга бу өлкәдә мәгълүматлылыкларын тирәнәйтергә һәм киңәйтергә ярдәм итә.**

БЕРЕНЧЕ ӘҢГӘМӘ

## Буыннар чылбыры өзелмәсә, киләчәккә өмет бар

Бүгенге көндә җөмһүриятебездә һәм аннан читтә татар мәктәпләрен торгызу, яшь буынны халкыбызның рухи һәм мәдәни хәзинәләре нигезендә тәрбияләү җитди бурычка әверелде. Мәктәпләрдә укыту-тәрбия эшен камилләштерү максаты белән халык педагогикасы хәзинәләреннән файдалану кирәклеге дә көн тәртибенә килеп басты. Чөнки милли мәктәпләрне торгызу, яшь буында милли үзаң формалаштыру һәм шуның аша туган телен. халкын ихтирам итүче, аның тарихын өйрәнергә омтылучы, үз милләтенең мәнфәгатьләре өчен янып-көеп йөрергә сәләтле шәхес тәрбияләүне халык педагогикасыннан башка күз алдына китерүе дә кыен Димәк, яшь буынны тәрбияләүдә гаять зур әһәмияткә ия булган гореф-гадәтләрне, традицияләрне торгызу, яңарту, үстерү чоры килеп җитте. Һәр укытучы, ата-ана, тәрбияче үзенең тырыш иҗади эшчәнлеге белән моңа зур өлеш кертә ала.

Нәрсә соң ул халык педагогикасы?

«Педагогика» сүзе һәркемгә аңлашыла. Ул яшь буынга белем һәм тәрбия бирү турындагы фән. Халык педагогикасын халык тарафыннан барлыкка китерелгән белем һәм тәрбия бирү тәгълиматы дип аңларга кирәк.

Һәр халыкның, шул исәптән татар халкының да, иң изге, һәрвакыт җәлеп итеп торган хыялы — һәрьяктан камил шәхес тәрбияләү.

Тарихи үсеш дәвамында хыял-идеалга омтылу юлында халыкның бала тәрбияләүгә карашлары, уй-фикерләре тупланып килгән. Бу гаҗәеп рухи хәзинә, өзлексез камилләшә барып, буыннан-буынга тапшырылган. Яңа буын гореф-гадәтләрне, йолаларны, халыкның телен-динен хөрмәтләп яшәгән, олыга — олы, кечегә кече дип караган. Картайган ата-анасын тәрбия кылуны, тудырган баласын багып үстерүне изге бурыч итеп санаган, рәнҗеш-каргыштан уттан курыккан кебек курыккан. Хак хаклый белгән безнең халык: алла хакын, ата-ана хакын, күрше хакын, тол-ятимнәр, ярлы-ябагалар хакын, милләт хакын...

Шулай халыкта гадәткә кергән карашлар, әхлак нормалары һәм мөнәсәбәтләр, йолалар барлыкка килгән.

Халык педагогикасын кайберәүләр кыска гына итеп «**этнопедагогика**» дип атый. Болай атау тәгәлрәк кебек Грек сүзе ethnos «халыкның матди һәм рухи культурасы, мәдәни-тарихи мөнәсәбәтләре, тормыш-көнкүреш, әхлак, зәвык үзенчәлекләре» дигәнне аңлата. Халык педагогикасының нигезенә дә һәр халыкның үзенә ге-
нә хас тәрбия алымнары, гореф-гадәтләре, йо
лалары, тормыш-көнкүрешен оештыру һәм үз
үзен тоту рәвеше, әхлак кагыйдәләре, аларны
милли үзенчәлекләре салынган. Болар бар д
буыннан буынга күчеп, милли традицияләрг
әверелгән Бала тәрбияләү тәҗрибәсе милләте
безнең көчен, акылын, зирәклеген, зәвыгы
мәдәниятен, хис-омтылышларын, яшәү үзенч
леген, мөнәсәбәтләрен чагылдыруы беле
кыйммәт. Шуны да искәртеп үтик. «бала тәрбі
яләү» төшенчәсен киң мәгънәдә, аң-белем бир
дип тә, тәрбия кылу дип тә аңларга кирәк. Бе
инде хәзер бу киң һәм тирән эчтәлекле пр
цессны «тәрбия» сүзе белән генә атарга күне
кәнбез.

Халык педагогикасы турында мәгълүматл
туплау чыганаклары бик күп төрле. Иң берен
чиратта — билгесез даһиларыбыз иҗат итк
мәкаль һәм әйтемнәр, табышмак һәм такма
лар, әкият һәм риваятьләр, мәзәкләр һәм маж
ралы хикәяләр, җырлар һәм дастаннар. Әб
бабаларыбыз, зыялы затларыбыз дөньяны
нып-белүләрен, тәҗрибәләрен, идеалларын,
хисләрен, теләк-омтылышларын башта — та
ка, күнгә, агач кайрысына, соңрак кәгазьгә,
тап итеп язып, аларны кулдан-кулга, буынн
буынга күчереп, мирас итеп калдырганнар.
генге көндә дә, бигрәк тә әби-бабайлар бе
бергәләп яшәгән гаиләләрдә балаларны хал
бызның күркәм традицияләренә нигезләнеп т
бияләүче ата-аналар аз түгел. Бу тәҗриб
өйрәнү өчен бигрәк тә авыл җирендә мөмк
лекләр күп. Чал тарихлы бай әдәбиятыбы
һәм гыйльми хезмәтләрдә дә халкыбызга
педагогик талант сокландыргыч, җанлы, дәли
итеп чагылдырылган

Берничә мисал.

Галимҗан Барудиның 1910 елда Казанда
сылып чыккан «Мәгарифе Исламия» исе
хезмәте мөселманнарның көндәлек тормы
үз-үзләрен тоту кагыйдәләренә аңлатмалар
тора. Аның башка китаплары һәм аның т
фыннан чыгарылган «Әл-дин вә Әл-әдәп»
налы (1906—1917 елларда чыга) тәрбия ме
ләләренә, кешенең рухи үсешенә кагылы
материалларга бай.

Күп кенә тарихи, әдәби һәм педагогик
мәтләрнең авторы, Көнчыгыш мәдәнияте
рәнүче галимнәрнең күренекле вәкиле Риз
хретдинов (1858—1936), балаларны тугач та
бияли башларга кирәк, дигән фикердә ны
рып, иң әүвәл ананы тәрбияләүгә зур әһ
бирә һәм «Тәрбияле хатын», «Тәрбияле
дигән хезмәтләрен яза. Өлкән яшьтәге ба
өчен «Шәкертләр әдәбе», кечә яшьтәге ба
өчен «Тәрбияле бала», шулай ук «Гаилә
исемләнгән хезмәтләрендә дә халыкның т

тәҗрибәсен яхшы белүе, аны ихлас күңелдән пропагандаларга омтылуы сизелә. «Шура» журналы (Риза Фәхретдинов аның баш мөхәррире була) «Тәрбия һәм тәгълим»[1] бүлеген дә биреп, анда даими рәвештә бай мәгълүматлар, акыл, киңәшләр, фикерләр, үрнәкләр урнаштырып бара.

Әдип, журналист, галим, педагог Фатих Кәрими (1870—1937) «Әзһәр әхлак» («Чын әхлак»), «Мәктәпкәчә тәрбия», «Иҗтимагый тәрбия» исемле һәм башка педагогик хезмәтләрендә «Җиһангир мәхдүмнең авыл мәдрәсәсендә укуы», «Бер шәкерт илә бер студент», «Салих бабайның өйләнүе», «Мирза кызы Фатыйма» кебек педагогик юнәлешле хикәяләрендә халыкның гыйлемне, укуны яратуын, балаларын ничек булса да укытырга омтылуын, мәктәп-мәдрәсәләрдә әдәп-әхлак тәрбиясе дә бирелергә тиешлеген, гади авыл картларының башкаларга, бигрәк тә бала-чагага көчле тәрбияви йогынтысын ышанычлы итеп ачып бирә.

Халыкның тәгълим-тәрбия тәҗрибәсендә уңай традицияләр тууында, ныгуында мәктәп-мәдрәсәләребез әһәмиятле эш башкара. Анда тептән, ятлый-ятлый, асыл тәпләренә тәшә-тәшә өйрәнелә торган «Нәсихәт-әссәлихин» китабы шәкертләребезне изге эшләргә өндәп торган. «Рәһбәр сыйбъян» (авторы — Зәбири Хәбибәр-Рахман), «Уку китабы яхуд вә вазаиф әфтәл» (Назыйм Гали), «Тәрбия китабы» (К. Насыйри), «Сабыйларга мәгълүмат» (Хәнәфия Әшрәф), «Малайлар һәм кызлардан ялкаулыкны җибәрү», «Сабый вә сабыяләр өчен мәргуб булган хикәяләр вә мәкальләр һәм олугларны тәрбия өчен гыйбрәтләр» (Таиб Яхин) кебек XIX йөзнең ахырында — XX йөзнең башында басылып чыккан күп сандагы уку китаплары балаларга сабый чактан ук тормышта кон дә кирәк була торган әдәп-әхлак нормаларын күңелләренә, рухларына сеңдергәннәр. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы, Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел фарадис»ы, Мөхәммәдъярның «Төхфәи мәрдан»ы һәм «Нуры содур»ы, Мәүла Колый хикмәтләре, Утыз Имәни бәяннары һ. б. йөзләгән буынны илгә, милләткә тугрылыклы булу, хезмәт, матурлык сөю, игелекле, кыю, батыр булу, *сәламәт, зирәк, сәләтле булырга омтылу*, киләчәгең турында да уйлап-кайгыртып яшәү рухында, якты идеалларда тәрбияләгәннәр. Мәдрәсәне тәмамлагач, мөгаллим, хәлфә, мөдәррис, мулла, хәзрәт үз белгәнен халыкка җиткергән. Укымышлы кешеләргә һәм китап сүзенә хөрмәт һәм ышаныч белән карый торган безнең татар халкы акыллы киңәшләрне зиһен һәм күңел төбенә сеңдереп куйган, файдалысын һәм хуш килгәнен, бигрәк тә көндәлек тормышка яраклысын көнкүрешендә гамәлгә керткән.

Безнең мәктәп-мәдрәсәләребездә кулланылган дәреслекләребез сәхифәләрендә сокланырлык бер нәрсә бар: ул да булса — аларның халык педагогикасы белән сугарылган булуы. Мәсәлән, әдәбият буенча уку китапларының һәрберсендә иң беренче бит мәктәпкә, аннан алга таба битләр анага, атага, мөгаллим-хәлфәләргә, якыннарга багышлана. Тормыш мәшәкатьләре, мал-туар, тереклек дөньясының изгелеге турында, әдәп-әхлак сыйфатларына кагылышлы мәкаләләр, хикәяләр, шигъри әсәрләр бар. Ата-ул, хәлфә-шәкерт, галим-хәлфә әңгәмәләре рәвешендә бирелгән материаллар тәрбия итү ысулларын да үз эченә алалар. Алар шәкертләрнең танып-белү сәләтен үстерү ягыннан да, тәрбия бирү чарасы буларак та әһәмиятле. Кыз балалар өчен махсус китапларда кызлык намусын — гыйффәтлелекне саклау, ана булуның җаваплылыгы, бала тәрбияләү кебек мөһим мәсьәләләр күтәрелә.

Ислам диненең халык педагогикасына көчле йогынтысын әйтми үтү дә дөрес булмас иде. Коръән, аның аерым сүрәләре, аятьләре, аларда бәян ителгән гыйбрәтле язмышлар — болар барысы да безнең әби-бабаларыбыз өчен кайгылы һәм хәсрәтле вакытларында юатучы, яхшыны яманнан аерырга өйрәтүче, тән һәм рух сәламәтлеген тәрбияләүче, аң-белемгә юл күрсәтүче булган. Кешенең барлыкка килүен, Җир йөзендә яшәү сәбәпләрен аңлаткан, тормышның мәгънәсен танып белергә ярдәм иткән сүрәләр бар. Коръәннең аерым киңәшләре тормыш, тереклек итүнең таяну ноктасы булып хезмәт иткәннәр. Революциягә кадәр Коръән барлык мәктәп-мәдрәсәләрдә укытылган. (Мөселман дәүләтләрендә ул хәзер дә мәктәп-мәдрәсәләрдә һәм югары уку йортларында төп фәннәрнең берсе.)

Халык педагогикасын мәктәпләр, укытучылар эшендә куллануга хәзер нык игътибар ителә. Бу уңайдан соңгы вакытта «Мәгариф» журналында басылган мәкаләләрне[2] күрсәтеп үтәргә мөмкин. Татарстан укытучылар белемен күтәрү институтының педагогика кафедрасында «Халык педагогикасы» лабораториясе оештырылу әлеге мөһим мәсьәләнең киң планда тикшерелүенә, башка милләтләрдәге кебек, калын-калын китаплар нәшер ителәчәгенә өмет тудыра.

Шул рәвешчә, халык педагогикасы, башка фәннәрдән аермалы буларак, фәнни тәгълимат та, шул ук вакытта буыннан-буынга тупланган һәр яңа буын тарафыннан камиллләштерелгән һәм баетылган тәҗрибә дә. Аның өйрәнү объекты үзенчәлекле: халыкның тәгълим-тәрбия традицияләре.

Тәгълимат буларак, халык педагогикасы алдында шундый катлаулы бурычлар тора:

— тарихыбызның буеннан-буена әби-бабаларыбыз, акыл ияләребезнең, әти-әниләребезнең ул-кызларны тәгълим-тәрбия итү ысулларын өйрәнү һәм аларны системага салу,

— балаларга, яшьләргә бирелгән үгет-нәсихәтләрнең, искәртү, кисәтү, мактау һәм хуплауларның эчтәлеген анализлау һәм аларга бүген көн кадагында булган мәсьәләләр күзлегеннән бәя бирү;

— яман гадәтләрдән, кыңгыр сыйфатлардан арындыру өчен нинди чаралар кулланылганын барлау;

— дингә, дин әһелләренә, туганлык мәсьәләләренә карата яшьләрдә уңай мөнәсәбәт булдыру үзенчәлекләрен билгеләү һ. б.

Тәҗрибә тупламы буларак, халык педагогикасы мондый бай һәм гыйбрәтле тәгълим-тәрбия традицияләрен үз эченә ала.

Иң беренче чиратта — хезмәт сөю, хезмәт кешесен олылау, балаларны хезмәттә тәрбияләү. Безнең халык бала тәрбияләү хакында махсус хезмәтләр укымаса да, үзенең шәхси

[1] Тәгълим — белемгә өйрәтү, гыйлемле итү дигән мәгънәдә кулланыла.

[2] М. Госманов, Б. Камал, Х. Батчаева, Н. Баягоз, Сункишева, Р. Шагаев, З. Хәбибуллина һ. б.ларның мәкаләләре күздә тотыла.

үрнәгендә һәм сабыр холыклы, әдәпле булуы сәбәпле, балаларда хезмәткә җитди мөнәсәбәт, һәр эшне тырышып, җиренә җиткереп башкарырга омтылыш тәрбияли алган.

Халыкта борын-борыннан туган илгә, туган җиргә, туган телгә мәхәббәт һәм сак караш, туганнарга, кардәш-ыруга, күрше-күләнгә хөрмәт һәм кайгыртучанлык күрсәтү яшәп килгән, нәсел тамырларын буыннан-буынга биреп, нәсел шәҗәрәсен төзү гадәти күренеш булган. Балада шулар нигезендә туганлык мөнәсәбәтләре формалашкан, ул аралашып үскән.

Гаиләдә ата-ана, әби-бабаны, өлкәннәрне зурлау, алар сүзен дөрес, үтәлергә тиешле, тәҗрибәле, күпне күргән кеше сүзе дип кабул итү, ата-анага үстергән-тәрбияләгән, кеше иткән өчен рәхмәтле булу, изгелеккә изгелек белән җавап бирергә әзер тору беркем өчен дә гаҗәп хәл булмаган.

Халкыбызның тәрбия идеаллары нәрсәдән гыйбарәт соң?

— Баланы тәртипле, тыйнак, гадел, кешелекле, тугрылыклы итеп күрәсе килү һәм бу максатка ирешүдә тиешле чаралар күрү, иң әүвәл ата-ананың, гаиләдәге өлкәннәрнең шул сыйфатларга ия булуы.

— Белемгә, гыйлемгә, мәгърифәткә омтылыш, «бишектән алып ләхеткә кадәр белем эстәү»не идеал итү, тәгълим-тәрбия эшен кешенең гомерлек юлдашы дип карау.

— Башка милләт халыкларына дустанә мөнәсәбәт, алар белән тыгыз аралашып яшәү, аларның тормышын, мәдәниятен, әдәбиятын, мәгърифәтен өйрәнеп, үз зиһенеңне, тәҗрибәңне баетырга, акылыңны камилләштерергә омтылу.

— Нәфислек, матурлык, чисталык-пакьлекне ярату; тормыш кирәк-яракларын дөрес куллану; бүлмәләрне зәвык белән җиһазлау; йорт-җир тоту рәвеше; кием-салым тегү, нәфислек һөнәрләре (читекче, кәләпүшче, чигүче, бәйләү-туку остасы һ. б.); кешеләрнең үз-үзен тотышы, килеш-килбәте, йөреш-хәрәкәтләр үзенчәлеге — болар бар да халыкта буыннан-буынга бирелүче тәрбиянең матур нәтиҗәләре.

Тормыш шартларына тиз җайлашу, мул, төпле, җитешле итеп яшәргә омтылу, исәп-хисап итәргә хирыслык, сәүдә эшләре, сатучылык бе-
лән шөгыльләнү һәм моны гаҗәеп оста, оты
итеп башкару, аерата зиһенле, акыллы, ты
булу, ирәнмәү, кешеләр, чит илләр белән ар
шып яшәргә ярату — электән килгән гүзәл
фатлар һәм аларны бүгенге буында да тә
ләү мөһим.

Кунакчыллык, ачык йөзле булу — та
халкының иң күркәм сыйфатларыннан бе
Кунак өй бусагасыннан атлап керүгә, хуҗа
күптән килгән гадәт буенча, бөтен эшләрен т
лап, аңа хөрмәт күрсәтә башлыйлар: урын
түрен бирү, юынганда яңа, чиста сөлге тәкъ
итү, азыкның иң тәмлеләре белән генә сый
урын-җирне йомшак, чиста итү, кунакның к
лен күрергә тырышу һ. б. Үзенә күрә кунакль
«законнары» да барлыкка килгән: «Кунак ки
ит пеше, ит пешмәсә, бит пешә», «Кунакны
өсте торып сыйла»... Кунак өчен дә кагыйдә
бар: «Сыйлаганның суын эч», «Кунак бул
тыйнак бул», «Кунак — хуҗаның ишәге» һ
Балалар боларның барысын да күрә-ишетә
үзләре дә «кунак-кунак» уйныйлар, яшьтән
нак карап, кунакта үз-үзләрен матур тота
күнегеп үсәләр. Болар — халыкның һәрьяк
үскән шәхес тәрбияләргә омтылышын чагыл
рган һәм моңа ирешү юлында туган тради
яләре.

Халкыбызның гыйлем-тәрбия бирү тәҗри
се күп гасырлардан килә. Борынгы Болгар
үләте чорларында ук яшьләргә белем бирә т
ган уку йортлары булган. Татар халкы үз
мышының иң авыр шартларында да үзенең м
тәп-мәдрәсәләрен саклап кала алган. Мәгъ
фәтчелек хәрәкәте киң таралып, аның педа
гик фикере һәм күнекмәләре тагын да бай
камилләшә барган. Октябрь революциясенә
дәр үк халкыбызның Россиядә иң алдын
урыннарның берсен алып торуы, күп санлы
дагоглар, әдипләр, галимнәр, мәдәният, җә
гать эшлеклеләре үстерүе — мактауга, гор
лануга лаек. Бу — халкыбызның зур эшл
башкарырга көче-куәте барлыгына дәлил.

**(Дәвамы бар.)**

**Сания ИСМӘГЫЙЛЕ**
**Фәйрүзә ИСМӘГЫЙЛЕ**
**АДПИ доцентла**

# Мөгаллимнәр нигә эш алыштыра

Соңгы елларда гомуми белем мәктәпләрендә укытучыларның эш алыштырулары ешайды. Тикшерү нәтиҗәләре күрсәткәнчә, педагогларның 24,4 проценты бер ел эшләгәннән соң ук башка белгечлеккә ия булу турында уйлый башлый. Шул сәбәпле республикабызда, гомумән, БДБ илләрендә дә мөгаллимнәр җитми. Россиядә, мәсәлән, ел саен барлык укытучыларның 9,8 проценты башка эшкә күчә. Мондый хәлне булдырмау — халык мәгарифе алдында торган мөһим бурычларның берсе.

Татарстанда педагогик кадрлар 4 югары уку йортында — Казан, Алабуга, Чаллы педагогия институтларында, Казан университетында әзерләнә. Шуны да әйтү урынлы булыр: югары белемле мөгаллимнәр һәм тәрбиячеләр саны арта
бара. Шуңа карамастан, мәктәп педагогик кад
ларга кытлык кичерә. Җөмһүриятебездә юга
һәм махсус урта белемле 20 меңнән артык п
дагог халык хуҗалыгының башка тармаклары
да эшли.

Педагогик кадрлар бигрәк тә яшь шәһәр м
тәпләрендә җитми. Моны Чаллы каласы ми
лында карап үтик. Билгеле булганча, монда м
галлимнәр торак белән тиешле дәрәҗәдә т
эмин ителми. Моннан тыш, социаль-көнкүре
культура хезмәте күрсәтү дә канәгатьләнерл
түгел.

Шәһәрдә халык, шул исәптән укучылар са
да арта бара. Әмма мәктәп биналары бик
төзелә. Шунлыктан балалар 2 сменада укы
ла. Болар өстәвенә классларда балалар са
40—45 кә җитә. Мондый шартларда төпле б
лем һәм тәрбия бирү аеруча кыенлаша...

Укытучы кадрларга булган ихтыяҗны киме
өчен, 1977 елда Чаллы шәһәрендә — педаго
училищесы, соңрак педагогия институты ач
ды. Чаллы мәктәпләре шушы уку йортлар